ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

«27» май 2020 ел № 165

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 октябрендәге 458 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең штат санына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе буларак «Психологик-педагогик медицина-социаль хезмәт оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 31 октябрендәге 427 номерлы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләренең штат саны турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 октябрендәге 458 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең штат санына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Логопед-дефектолог» вазыйфасы белән «1» штат берәмлекләре санында тулыландырырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенә Россия Федерациясе Хезмәт кодексында каралган оештыру чаралары үткәрергә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) «Документлар» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе **А.С. Авдеев**